Гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында мәгълүмат

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнардан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен үтәү буенча торак күзәтчелеген һәм лицензия контролен Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе гамәлгә ашыра.

2018 елның 6 ае өчен үткәрелгән планлы тикшерүләр барышында муниципаль берәмлекләрдә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын арттыру фактлары (алга таба – чик индекслар) ачыкланмады.

2018 елның 6 аенда, чик индексларны арттыру фактлары предметына карата планнан тыш тикшерүләр әлеге тикшерүләрне уздыру өчен нигезләр булмавы аркасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан үткәрелмәде.